ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**24.04.2025**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 1120**

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск муниципаль районы муниципаль мәгариф оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәләрне раслау хакында» 2024 елның 19 июлендәге 1899 номерлы карары кушымтасына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 ел, 31 май, 412 нче карары белән расланган, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елның 30 декабрендәге «Татарстан Республикасы дәүләт белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 1273 номерлы карарын, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 ел, 31 май, 412 нче карары белән расланган,Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2025 елның 12 мартындагы 149 номерлы карарын үтәү йөзеннән, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск муниципаль районы муниципаль мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәләрне раслау хакында» 2024 елның 19 июлендәге 1899 номерлы карары кушымтасына (алга таба - карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «Зеленодольск муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында нигезләмә»гә (Карарның 1 нче кушымтасы), әлеге карарга 1 нче кушымтада каралганча;

1.2. «Зеленодольск муниципаль районы мәктәпкәчә мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчентүләү шартлары турында нигезләмә»гә (Карарның 2 нче кушымтасы), әлеге карарга 2 нче кушымтада каралганча.

2. Учреждение җитәкчеләренә үзләренең локаль актларын әлеге карарга туры китерергә.

3. Әлеге карарның гамәлдә булуын 2025 елның 01 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә таратырга.

4. Әлеге карарны Зеленодольск муниципаль район Советы аппаратының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә «Интернет» челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми (http://pravo.tatarstan.ru ) порталында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр составындагы Зеленодольск муниципаль районы мәгълүмат (http://zelenodolsk.tatarstan.ru ) сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче З.Ф. Хәбибуллин

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2025 елның 24 апрелендәге
1120 номерлы карарына
1 нче кушымта

5.2 пунктындагы 5.2.1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"5.2.1. Квалификация категориясе өчен түләүләр педагогик хезмәткәрләр һәм структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазифаларының һөнәри квалификация төркеме хезмәткәрләренә, аларның гамәлдәге квалификация категориясе булган очракта, квалификация категориясенең гамәлдә булу вакыты чикләрендә бирелә.

Квалификация категориясе өчен түләүләрне билгеләү (үзгәртү) тиешле аттестация комиссиясе тарафыннан уңай карар кабул ителгән көннән гамәлгә ашырыла.

Квалификация категориясе өчен түләүләр (Bkk) башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы педагогик хезмәткәрләрнең һәм структур бүлекчәләр җитәкчеләренең һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренә бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$B_{kk} = O_d \times \frac{D_{kk}}{100\%},$$

биредә:

$O_d$ - гомуми белем бирү оешмаларының башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_{kk}$ – – 1 нче таблицада китерелгән квалификация категориясе өчен өстәмә түләү күләме.

1 нче таблица

Башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирүне гамәлгә ашыручы мәгариф хезмәткәрләренә квалификация категориясе өчен өстәмә түләүләр күләмнәре

| Квалификация дәрәҗәсе | Квалификация категориясе | Өстәмә түләү күләме, процентларда |
|---|---|---|
| Педагогик хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме . | | |
| | Беренче квалификация категориясе | 10,0 |
| | Югары квалификация категориясе | 22,0 |
| Икенче | Беренче квалификация категориясе | 12,0 |
| | Югары квалификация категориясе | 24,0 |
| Өченче | Беренче квалификация категориясе | 12,0 |
| | Югары квалификация категориясе | 24,0 |
| Дүртенче | Беренче квалификация категориясе | 12,0 |
| | Югары квалификация категориясе | 24,0 |

| Структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
|---|---|---|
| Беренче | Беренче квалификация категориясе | 12,0 |
| | Югары квалификация категориясе | 24,0 |
| Икенче | Беренче квалификация категориясе | 12,0 |
| | Югары квалификация категориясе | 24,0 |
| Өченче | Беренче квалификация категориясе | 12,0 |
| | Югары квалификация категориясе | 24,0 |

әлеге Нигезләмәгә теркәлгән 1 нче кушымтаның "Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының (Совет Социалистик Республикалар Союзының, Россия Совет Федератив Социалистик Республикасының) стимуллаштыру характерындагы түләүләр бирелә торган ведомство бүләкләре" бүлегенең 1 бүлекчәсенә түбәндәге эчтәлекле 1.20 пункт өстәргә:

| | |
|---|---|
| "1.20. | "Мактаулы остаз" күкрәк билгесе. |

17 нче таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итеп:

"17 нче таблица

Гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләренең хезмәте өчен түләү буенча төркем, база окладлары күләмнәре һәм җитәкчегә башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләр

| Җитәкче хезмәте өчен түләү буенча төркем | Күләм күрсәткеченең зурлыгы (уку елы башына карата укучылар, тәрбияләнүчеләр саны), кеше* | База оклады, сум | Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләр, сум |
|---|---|---|---|
| 1 | 1 - 15 | 37 000 | 8 000 |
| 2 | 16 - 50 | 39 000 | 8 000 |
| 3 | 51 - 100 | 41 000 | 9 000 |
| 4 | 101 - 200 | 42 000 | 10 000 |
| 5 | 201 - 400 | 43 000 | 11 000 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 6 | 401 - 600 | 44 000 | 12 000 |
| 7 | 601 - 800 | 45 000 | 12 000 |
| 8 | 801 - 1 000 | 48 000 | 12 000 |
| 9 | 1 001 - 1 200 | 49 000 | 13 000 |
| 10 | 1 201 - 1 400 | 50 000 | 14 000 |
| 11 | 1 401 - 1 800 | 50 000 | 17 000 |
| 12 | 1 801 һәм аннан югарырак | 51 000 | 20 000 |

--------------------------------

<*> Девиант тәртипле белем алучылар өчен ябык типтагы гомуми белем бирү оешмалары, җинаять-үтәтү системасының төзәтү учреждениеләре каршындагы гомуми белем бирү оешмалары, озак дәвалануга мохтаҗ балалар өчен шифаханә тибындагы гомуми белем бирү оешмалары, җайлаштырылган уку-укыту программаларын гамәлгә ашыручы гомуми белем бирү оешмалары укучылары контингенты 3 коэффициенты белән исәпкә алына.

Гомуми белем бирү оешмалары каршындагы интернатларда яшәүче укучылар контингенты 2 коэффициенты белән исәпкә алына.

Гомуми белем бирү оешмаларының мәктәпкәчә төркемнәрендә тәрбияләнүчеләр контингенты 1,5 коэффициенты белән исәпкә алына.

Мәктәпара уку-укыту комбинатларында укучылар контингенты 0,5 коэффициенты белән исәпкә алына".

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2025 елның 24 апрелендәге
1120 номерлы карарына
2 нче кушымта

5.2 пунктындагы 5.2.1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"5.2.1. Квалификация категориясе өчен түләүләр педагогик хезмәткәрләр һәм структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазифаларының һөнәри квалификация төркеме хезмәткәрләренә, аларның гамәлдәге квалификация категориясе булган очракта, квалификация категориясенең гамәлдә булу вакыты чикләрендә бирелә.

Квалификация категориясе өчен түләүләрне билгеләү (үзгәртү) тиешле аттестация комиссиясе тарафыннан уңай карар кабул ителгән көннән гамәлгә ашырыла.

Квалификация категориясе өчен түләүләр ($B_{kk(d)}$) педагогик хезмәткәрләр һәм гомуми белем бирү оешмаларында мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыра торган структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазифаларының һөнәри квалификация төркеме хезмәткәрләренә бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$B_{kk(d)} = O_d \times \frac{D_{kk(d)}}{100\%},$$

биредә:

$O_d$ - гомуми белем бирү оешмаларының мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_{kk(d)}$ - 1.1 нче таблицада китерелгән квалификация категориясе өчен өстәмәл түләү күләме.

1.1 нче таблица

Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф хезмәткәрләренә квалификация категориясе өчен өстәмә түләүләр күләмнәре

| Квалификация дәрәҗәсе | Квалификация категориясе | Өстәмә түләү күләме, процентларда |
|---|---|---|
| Педагогик хезмәткәр вазифаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче | Беренче квалификация категориясе | 25,0 |
| | Югары квалификация категориясе | 30,0 |
| Икенче | Беренче квалификация категориясе | 26,0 |
| | Югары квалификация категориясе | 31,0 |

| | | |
|---|---|---|
| Өченче | Беренче квалификация категориясе | 27,0 |
| | Югары квалификация категориясе | 32,0 |
| Дүртенче | Беренче квалификация категориясе | 28,0 |
| | Югары квалификация категориясе | 33,0 |
| Структур бүлекчә җитәкчеләре вазифаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче | Беренче квалификация категориясе | 28,0 |
| | Югары квалификация категориясе | 34,0 |
| Икенче | Беренче квалификация категориясе | 28,0 |
| | Югары квалификация категориясе | 34,0 |
| Өченче | Беренче квалификация категориясе | 28,0 |
| | Югары квалификация категориясе | 34,0"; |

әлеге Нигезләмәгә теркәлгән 1 нче кушымтаның “Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының (Совет Социалистик Республикалар Союзының, Россия Совет Федератив Социалистик Республикасының) стимуллаштыру характерындагы түләүләр бирелә торган ведомство бүләкләре" бүлегенең 1 бүлекчәсенә түбәндәге эчтәлекле 1.20 пункт өстәргә:

| | |
|---|---|
| "1.20. | "Мактаулы остаз" күкрәк билгесе. |